ГЛАВА СТАРОКАШИРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
03 ноябрь 2020 ел

КАРАР
№ 2

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Урта Кәшер авылында үзара салым акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы:

1.Урта Кәшер авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 13 ноябренә 16.00 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:«2021 елда Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, хәрби хезмәттәге хәрбиләрдән тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- Җиңү көне, , өлкәннәр көне ,, Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу; ;
- Урта Кәшер авылында Боек Ватан сугышында катнашучылар хәм сәяси репрессия корбаннары истәлегенә хәйкәл салу;;
- светодиод яктырткычлар урнаштыру ;
- МТЗ-82 тракторын карап тоту( ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу););
- авыл җирлеге торак пунктларындагы юлларны кыш көне кардан чистарту, җәйге вакытта үләннәрне чабу, тәзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен түләү.;- агач кисү;
- зират өчен инвентарь р сатып алу ; ; - «Сарман»район газетасына некрологларны бирү.

ӘЙЕ ЮК?».

3.Иске Кәшер авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO) урнаштырырга. TATARSTAN.RU Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Дәүләтҗанов